**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.02.2016 № 61

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 4 февралендә теркәлде, № 3207

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүне камилләштерү максатыннан **боерык бирәм**:

1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 26.06.2015 ел, № 435 боерыгы белән расланган административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4.2 пункттан "1.5," цифрларын төшереп калдырырга;

1.5 пунктның 6 нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 ел, № 528н "Федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелүче Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын төзү һәм тормышка ашыру тәртибен, һәм аларның формаларын раслау турында" боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет порталы, http://www.pravo.gov.ru, 24.08.2015);";

1.5 пунктның унынчы абзацын "гражданинны" сүзеннән соң "социаль хезмәт күрсәтүгә" сүзләре белән тулыландырырга;

1.5 пунктның унөченче абзацын "(алга таба – № 1101 ТР МК карары белән расланган Тәртип)" сүзләреннән соң "(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2015, № 34-35, 1171 ст.)" сүзләре белән тулыландырырга;

таблицаның 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору ихтималы Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында яисә социаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар гариза бирелгән көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә.<br>Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кичекмәстән кабул ителә.<br>Гражданинга социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү һәм бирү гариза бирелгән көннән алып ун эш көненнән артмаган срокта башкарыла.<br>Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы төзелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган. | № 442-ФЗ Федераль законның 15 ст. 2 өл.<br>№ 442-ФЗ Федераль законның 16 ст. 4 өл.<br>№ 442-ФЗ Федераль законның 21 ст. 2 өл.”; |

таблицаның 2.6 пунктында “Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт” графасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“№ 210-ФЗ Федераль законның 7 ст. 1 өл. 2 п.”;

икенче абзацны төшереп калдырырга;

таблицаның 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законына туры китереп, | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидның дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | каршылыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга каршылыксыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга бару максатыннан, объект эчендә бер урыннан бер урынга мөстәкыйль күчеп йөрү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып.”; | |

Регламентка 1 нче кушымтада:

таблицаның 3 пунктындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән инвалидлар өчен), яисә Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасы”;

таблицаның 3 пунктындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 2 нче кушымтада:

таблицаның 3 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалидлар өчен), яисә Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасы”;

таблицаның 3 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү

чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 3 нче кушымтада:

таблицаның 3 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалидлар өчен), яисә Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасы”;

таблицаның 3 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 4 нче кушымтада:

таблицаның 3 пунктындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалид баланы тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалид балалар өчен), яисә Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасы”;

таблицаның 3 пунктындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалид баланы тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 5 нче кушымтада:

таблицаның 3 пунктындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалидлар (инвалид балалар) өчен), яисә Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасы <**>”;

таблицаның 3 пунктындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы

йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

7 нче кушымтадагы таблицаның 3 пунктындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“белешмә нигезендә инвалидлык билгеләнгән чор тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 9 нчы кушымтада:

таблицаның 3 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалидлар (инвалид балалар) өчен), яисә Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасы <**>”;

таблицаның 3 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 10 нчы кушымтада:

таблицаның 2 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябренә кадәр төзелгән һәм бирелгән, яисә Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм бирелгән инвалидлар (инвалид балалар) өчен), яисә Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Россия Федерациясенең башка субъектында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасы <**>”;

таблицаның 2 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 11 нче кушымтада:

таблицаның 1 пунктындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән башлап 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда төзелгән һәм бирелгән инвалидлар өчен), яисә Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Татарстан Республикасында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасыннан өземтә”;

таблицаның 1 пунктындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки

Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 12 нче кушымтада:

таблицаның 3 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән башлап 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда төзелгән һәм бирелгән инвалидлар өчен), яисә Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Татарстан Республикасында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасыннан өземтә”;

таблицаның 3 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 13 нче кушымтада:

таблицаның 3 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән башлап 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда төзелгән һәм бирелгән инвалидлар өчен), яисә Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Татарстан Республикасында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасыннан өземтә”;

таблицаның 3 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 14 нче кушымтада:

таблицаның 3, 4 һәм 6 пунктларын тиңдәшле рәвештә 1, 2 һәм 3 пунктлар дип санарга;

таблицаның 3 пунктындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Министрлыкның территориаль органы мәгълүмат базасында торучы, Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән башлап 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда төзелгән һәм бирелгән Инвалид баланы тернәкләндерүнең индивидуаль программасы, яисә Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Татарстан Республикасында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасыннан өземтә”;

таблицаның 3 пунктындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалид баланы тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 15 нче кушымтада:

таблицаның 1 пунктындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән башлап 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда төзелгән һәм бирелгән инвалидлар (инвалид балалар) өчен), яисә Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Татарстан Республикасында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасыннан өземтә”;

таблицаның 1 пунктындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 19 нчы кушымтада:

таблицаның 3 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән башлап 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда төзелгән һәм бирелгән инвалидлар (инвалид балалар) өчен), яисә Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Татарстан Республикасында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасыннан өземтә <**>”;

таблицаның 3 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”;

Регламентка 20 нче кушымтада:

таблицаның 2 юлындагы 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасы (ИПР Татарстан Республикасында 2011 елның 30 октябреннән башлап 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда төзелгән һәм бирелгән инвалидлар (инвалид балалар) өчен), яисә Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең Татарстан Республикасында төзелгән һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелгән индивидуаль программасыннан өземтә <*>”;

таблицаның 2 юлындагы 4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең индивидуаль программасында яки Инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль тернәкләндерү яки абилитацияләү чараларын уздыруга мохтаҗлыгы турындагы йомгаклау нәтиҗәсенең үтәлү срогы тәмамланганга кадәр”.

2. Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.11.2015 ел, № 831 боерыгы белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

таблицаның 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору ихтималы Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителә торган максималь сроклары:<br>шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, 15 минуттан артмаска тиеш;<br>телефон аша шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, 10 минуттан артмаска тиеш;<br>язмача мөрәҗәгать иткәндә, шул исәптән электрон почта аша – мөрәҗәгать теркәлгән моменттан 22 эш көненнән артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган.”; | |

таблицаның 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| яклау турындагы законына туры китереп, әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Инвалидның дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарыннан каршылыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга каршылыксыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга бару максатыннан, объект эчендә бер урыннан бер урынга мөстәкыйль күчеп йөрү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып.”. | |

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**